Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Лашман авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены

**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге
составына керүче Лашман, Әмир торак пунктларында

27 октябрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегендә халык җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Лашман авыл җирлеге территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш.

2. Алынган чараларны түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Лашман, Әмир торак пунктларында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү , кулланылган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Лашман, Әмир торак пунктларында җирле әһәмияттәге урам юлларының чокырларын ремонтлау, ясалма тигезсезлек төзү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабуга, юлларны грейдерлауга, юлларны кыш көне кардан чистартуга) Лашман, Әмир торак пунктларында, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алуга,
тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакына, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу өчен чыгымнар;
- Лашман, Әмир авылларында халык күпләп ял итә алсын өчен шартлар тудыру һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү;
- Лашман ,Әмир торак пунктларында чишмәләрне ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Лашман авылы, Совет ур., 55 йорт, Әмир авылы, Мәктәп ур., 61, Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең рәсми интернет-сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Лашман авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Фәттахов